СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

12 МАРТ, 1997ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 27 (8039) | Бәясе билгеләнгәнчә.

## КҮҢЕЛ ИТКӘНДӘ БУЛА ИКӘН

### *(Терлекчелек буенча семинар - киңәшмәдән)*

**Өченче тапкыр инде терлекчелектә айлык эш йомгакларын тикшерүгә багышланган семинар киңәшмәләр кайсы да булса берәр хуҗалыкка барып уздырыла. Болай эшләүнең төп максаты тармакта эш оештыруның, малларны карау һәм ашатуны технология таләпләренә туры китереп алып баруның нәтиҗәләрен бу эшкә турыдан - туры катнашы булган кешеләргә үз күзләре белән күрү, анда күргәннәрен үз хуҗалыкларындагы белән чагыштырып карау һәм моннан тиешле нәтиҗә ясау мөмкинлеге тудырудан гыйбарәт. Ә нәтиҗә ясауга килгәндә, әле күп кенә хуҗалыкларда терлекчелектә эшне тиешле югарылыгына кую өчен нык тырышасы бар. Быелның ике айлык йомгакларын анализлау өчен «Үрнәк» крестьян һәм фермер хуҗалыклары ассоциациясендә уздырылган семинар - киңәшмә дә бу яктан шактый ук гыйбрәтле булды.**

Җыелу урыны итеп нәкъ менә шушы хуҗалык сайлануы очраклы түгел иде. Мәгълүм булганча, былтыр «Путь к коммунизму» һәм «Үрнәк» КХАләре соңгысының исеме астында берләштеләр. Сер түгел, соңгы вакытта аларның икесендә дә терлекчелектә мактарлык нәрсә калмаган иде диярлек. Шуңа да хуҗалыкларны берләштерү, тармакта эшне җайга салу зарурлыгын бар кискенлегендә кую юкка түгел иде. Бәхеткә каршы, юкка булмады да. Иң мөһиме - берләштерелгән хуҗалык җитәкчелеге ике бүлекчәдә дә терлекчелектә мал асрау һәм ашатуны бүген республикада һәм районда көн үзәгенә куелган таләпләргә җавап бирерлек итеп оештыру эшенә чын - чынлап алынган һәм хәзер аның нәтиҗәсе күз алдында. Аның семинар - киңәшмәгә җыелган хуҗалык җитәкчеләре, баш зоотехниклар һәм ветеринария табиблары да үз күзләре белән күрделәр. Күңел иткәндә, эштә тәртип салуга чынлап торып алынганда нинди генә кыен хәлләрдән дә чыгып була икән бит. (Бу хакта семинарда авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең терлекчелек буенча баш белгечләре Ф.Г.Минһаҗев һәм Р.С.Гыйлаҗев, хуҗалык рәисе В.И.Гаврилов тәфсилләп сөйләделәр). Әнә, малларны бәйләмичә асрау өчен яңа абзар - мазар да төзеп тормаганнар (хәзер генә аңысына вакыты да, аннан бигрәк акчасы да юк), булган абзарларда иң гади үзгәртүләр үткәргәннәр дә, савыла торган һәм ташлаткан сыерларны аерым - аерым асрау мөмкинлеге дә табылган, кардалар корамалап, симертүдәге үгез - таналарны яшьләре буенча да аерым урнаштыра алганнар. Яңа туган бозауларны салкында үстерү мәсьәләсендә дә аптырап калмаганнар - салкын абзарлар эчендә үк берәр бозаулык та, группалап асрарлык та итеп читлекләр эшләгәннәр дә, яшь маллар шуларда рәхәтләнеп үсеп яталар. Сезгә - ялган, безгә - чын дигәндәй, кышка кергәч яңача шартларда туган һәм салкында асрала торган бозаулар былтыр көз иске ысул белән асрау шартларында туган һәм тотылганнарын буйга да куып җитеп киләләр, карап торышка да күз генә тимәсен үзләренә. Ә иң мөһиме - нәтиҗәдә быел хуҗалыкта бозау алу күзгә күренеп арткан һәм яшь үрчемнең саклануы яхшы. Димәк, куйган тырышлыклары бушка китмәгән. Ә тырышуын чыннан да аз тырышмаганнар биредә. Бозауларның барысын да салкында асрауга ирешү өчен бер абзарда читлекләрне кыш буена өч тапкыр үзгәртеп корырга туры килгән. Аның каравы, хәзер фермаларда карда тулы яшь мал. Анда аларга саламы - печәне дә китерелгән, оны - суы бирү мәсьәләсе дә хәл ителгән. Һәм тагын бер мөһим нәтиҗә шул - малларны асрау гадиләштерелгәч, эшче кулларга ихтыяҗ кимегән һәм хәзер кайберәүләрне (шуңа лаеклыларын, әлбәттә) кыскарта да башлаганнар. Соңгы елларда фермада эшләргә кеше таба алмый интегелгән «Путь к коммунизму» хуҗалыгында бит бу!

Шулай булгач, семинар - киңәшмәнең бу хуҗалыкта оештырылуы һич тә юкка түгел иде. Ике айлык эш нәтиҗәләрен анализлаган район авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе башлыгы Ә.Н.Рәхмәтуллин чыгышында да «Урнәк» нигездә уңай яктан гына телгә алынды.

Нәтиҗәләргә килгәндә, яңа елда районда терлекчелек, беренче чиратта сөт терлекчелеге тармагында хәл нигездә уңай булып кала килә. Аерым алганда, сыерлардан үрчем алу, бозауларның саклануы, шулай ук сөт җитештерү һәм аны дәүләткә сату мәсьәләләрендә хәл канәгатьләнерлек. Оратор бу юнәлештә нәтиҗәле генә эшләүче хуҗалыкларны да, күрсәткечләре шактый читенке булганнарын да әйтеп үтте. Соңгылары моннан тиешле нәтиҗә ясарлар дип ышанасы килә. Ә тармакта эшне тагын да яхшырту буенча уйланыр нәрсәләр шактый. Бу беренче чиратта күп кенә хуҗалыкларда малларның, бигрәк тә яшь үрчемнең саклануын яхшырту, сыерларны карау һәм ашату технологиясе таләпләрен үтәүгә җитди карап, сөт җитештерүне арттыру зарурлыгына кагыла. Бер үк вакытта малларның баш санын һич югы 1995 елгы дәрәҗәгә җиткерү дә мөһим бурыч булып тора. Болар һәммәсе терлекчеләр алдында торган тагын бер мөһим бурыч - ит җитештерү һәм хәзерләүдә билгеләнгән үрләргә чыгуга ирешү максатыннан да гаять әһәмиятле. Ә соңгысы әле шактый гына хуҗалыкларда һич тә уңайдан түгел. Киңәшмәдә һәм мөгезле эре терлекләрдән, һәм дуңгызлардан артым алу гафу ителмәслек дәрәҗәдә түбән булган хуҗалыклар телгә алынды.

Ит җитештерүне арттыруда мөһим резерв булган дуңгызчылык тармагында эшне җайга салу, моның өчен беренче чиратта язгы - җәйге үрчем алу чорына әзерләнү мәсьәләләренә киңәшмәдә аерым игътибар бирелде. Бу өлкәдә күп хуҗалыкларда шактый тырышасы бар әле.

Терлекчелекнең бу ике тармагында да бүген көнүзәк бурычларның берсе - малларны каплатуны уңышлы тәгәлләү. Бер үк вакытта нәсел эше, бу мәсьәләдә төгәл учет, ныклы тәртип булдыру турында да кайгыртырга кирәк. Шул чакта гына киләсе һәм аннан алдагы елларга да ышаныч белән карарга мөмкин булачак.

Киңәшмәдә сарыкчылыкта эшнең торышы да анализланды һәм бу тармакка һич тә кул селтәргә ярамаганлыгы искәртелде.

Терлекчелек продуктларының сыйфаты турында да кайгырту зарурлыгы хакында киңәшмәдә авыл хуҗалыгы продуктлары хәзерләү һәм сыйфат буенча баш дәүләт инспекторы Н.И.Фомин чыгыш ясады. Ул шулай ук индивидуаль сектордан сөт хәзерләүнең барышына да тукталды. Ветеринария - бактериология лабораториясе директоры Ш.Ш.Шарапов чыгышы мал авыруларына каршы профилактика эшенә җитди игътибар бирү зарурлыгы хакында иде.

Семинар - киңәшмәдә шулай ук язгы кыр эшләренә әзерлек мәсьәләләре хакында да зур сүз булды. Хакимият аппараты җитәкчесе Ф.М.Галимов районда Татарстан Республикасы Дәүләт Советына сайлауларга әзерлек мәсьәләләрен яктыртты.

Киңәшмә эшенә район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев йомгак ясады. Ул терлекчелектә ирешелгәннәрне ныгыту, алынган юнәлешне саклаган хәлдә продукция җитештерүне тотрыклы төстә арттыра бару, шул ук вакытта тармакта чыгымнарны кискен киметүгә юнәлдерелгән технологияләрне киң куллану буенча алда торган мөһим бурычларга җентекләп тукталды.

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ.**

### *Мактаулы исем*

Авыл хуҗалыгы өлкәсендәге уңышлары өчен мөгезле эре терлек симертү буенча Октябрь хуҗалыкара берләшмәсе директоры ( хәзер - «Кондырча» күмәк хуҗалыгы рәисе) **Йосыф Галиулла улы ӘХМӘТСАФИНГА** «Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

### 30 март - сайлау көне

## *ЧИРАТТАГЫ КИҢӘШМӘ*

**Шушы көннәрдә район хакимиятендә җирле үзидарә Советлары хезмәткәрләре, участок сайлау комиссияләре рәисләре һәм секретарьлары, кайбер тармак җитәкчеләре катнашында узган киңәшмәдә 50 нче Октябрь административ - территориаль сайлау округыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына сайлауга әзерлекнең беренче чираттагы мәсьәләләре каралды. Киңәшмәдә район хакимиятенең аппарат җитәкчесе Ф.М.Галимов, район сайлау комиссиясе рәисе Н.Х.Абдуллин, комиссия секретаре В.Г.Хоменко, Норлат җирле үзидарә Советы рәисе урынбасары В.Н.Ботрякова чыгыш ясадылар.**

### Бәйрәм тантаналары

## «ЧӘЧӘК БҮЛӘК ИТИК ГҮЗӘЛ ЗАТКА!»

Район мәдәният йортында үтә торган чаралар арасында хатын - кызларга багышланганнары һәрчак аерым бер күтәренкелек, күңел җылысы белән сугарылган була. Бу юлы да шулай булды.

Гүзәл затларыбызны бәйрәм белән иң элек район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин котлады. Ул хатын - кызларга районның социаль - икътисадый үсешенә керткән өлешләре өчен зур рәхмәт белдерде, алар адресына ихлас котлау сүзләре әйтте. Хакимият башлыгы шәһәрнең 3 нче урта мәктәбе укытучысы Ю.П.Шартынова «Татарстанның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирелүе турында грамота һәм чәчәкләр тапшырды.

Хакимият башлыгы урынбасары Ф.Р.Ногъманова хатын - кызларның производствода һәм районның иҗтимагый - сәяси тормышындагы роле турында сөйләгәннән соң кичәнең концерт өлеше башланды. Бу көнгә махсус әзерләнгән программага «Татарстан - минем республикам» һәм «Чуваш сандугачы - 97» республика конкурсларында дипломант һәм лауреат исемен алган коллективлар - балалар музыка мәктәбеннән балалар, «Родник» халык ансамбльләре, сәхнә ветераны Сания Котдусова, яшь башкаручылар К.Сайбаталова, Э.Әбделманова, Э.Хәмәтвәлиева һәм башкалар чыгыш ясады. Һәм, билгеле инде, бу концертта ир - ат башкаручылар күп булды. Сабит Миннеханов һәм Сәмигулла Рәхмәтуллинның баяннарда уйнап җырлаулары, гүзәл затларыбызга багышланган шигырьләр дә күңелләргә хуш килерлек иде. Кичәдә тынлы оркестр уйнады.

***

Шул ук көнне районның хезмәт коллективларында да хатын - кызларны бәйрәмнәре белән ихластан котладылар.

## *Сау бул, кыш, - исәнме, яз!*

Март - кышны озату, язны каршы алу ае. Узган якшәмбедә Норлатта һәм район авылларында узган масленица бәйрәме әнә шуның бер бизәге булды. Көне дә сорап алгандай матур килде, шуңа да шәһәрнең үзәк мәйданына халык гаять күп җыелды. Борынгыдан килгән бу бәйрәмнең программасы аның инде оныла барган нечкәлекләрен дә искә алып төзелгән иде һәм халык рәхәтләнеп күңел ачты, исәкәйләрне дә, үзешчән артистларны да бик җылы кабул итте. Балалар исә кыңгыраулы атларда урам әйләнделәр. Һәм, билгеле инде, масленица коймаксыз булмый - бу көнне дә табадан гына төшкән беленнәрдән авыз итәргә мөмкин иде.

## Кайда күпме сөт савалар?

**Саннарның беренче баганасы - район хуҗалыкларында быелның 10 мартында бер сыердан савылган сөт, икенчесе - узган елның шул көнендәгедән артык яки ким (килограммнарда), өченчесе - товарлылыгы (процентларда)**

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Дуслык» | 21,6 | + 8,4 | 82 |
| «Кондырча» | 16,0 | + 7,2 | 94 |
| Мичурин исем. | 12,0 | + 3,7 | 80 |
| «Рассвет» | 10,6 | + 2,7 | 78 |
| «Сөлчә» | 10,5 | + 2,5 | 87 |
| «Восход» | 10,0 | + 7,1 | 85 |
| Якты Күл | 10,0 | + 4,4 | 78 |
| «Чирмешән» | 9,8 | + 2,4 | 84 |
| Хафизов исем. | 9,5 | + 1,0 | 80 |
| «Родина» | 9,2 | + 1,1 | 93 |
| Муса Җәлил исем. | 9,0 | + 2,2 | 84 |
| «Заветы Ильича» | 8,8 | + 1,6 | 79 |
| «Чишмә» | 8,4 | + 2,3 | 84 |
| «Төрнәс» | 8,3 | + 3,2 | 79 |
| «Татарстан» | 8,2 | + 1,3 | 89 |
| Киекле | 7,9 | + 2,7 | 85 |
| «Москва» | 7,7 | + 1,7 | 77 |
| «Үрнәк» | 7,5 | + 1,6 | 81 |
| Синдряков исем. | 7,5 | + 0,9 | 82 |
| «Заря» | 7,4 | + 3,7 | 85 |
| Кузнецов исем. | 6,8 | + 0,9 | 82 |
| «40 лет Победы» | 6,7 | + 1,3 | 78 |
| «Игенче» | 6,3 | + 1,7 | 83 |
| «Строитель» | 6,2 | + 0,9 | 65 |
| Әлмәт | 6,0 | + 0,7 | 81 |
| «Правда» | 5,8 | + 2,2 | 62 |
| «Мамык» | 5,8 | + 0,8 | 76 |
| «Таң» | 5,3 | + 1,1 | 70 |
| «Комбайн» | 5,0 | + 1,2 | 84 |
| «Алга» | 4,5 | + 0,9 | 80 |
| **Район буенча** | **8,1** | **+ 2,0** | **81** |

## Тирәбездә яхшы кешеләр

# ҖАНЫ САУ БУЛГАЧ...

Дөнья бәясе торырлык кеше дип, нәкъ менә Һади ага кебекләр турында әйтәләрдер, мөгаен. Яшьлеге авыр елларга туры килде аның. Кул арасына керә генә башлаган елларында сугыш чыккач, фронтка киткән әтисе һәм абыйлары урынына калып, җир сөрде, иген үстерде ул. Яшьтәшләреннән бер ягы белән дә аерылмады, эшкә карусыз булды. Хәер, тулы бер авыл аның кебек әле беләкләре ныгырга да өлгермәгән яшүсмер малайлар, хатын - кызлар һәм карт - коры өстендә калганда башкача булуны күз алдына да китерми иде ул. Ә явыз дошманга карата нәфрәте сөйләп аңлатып кына була торган түгел иде. Шуңа 1944 нче елда 17 яше тулуга ук кулына корал тотып, фашистларга каршы көрәшү өчен фронтка китте ул. Ә анда күргән мәшхәр әле дә төшләренә кереп азаплый аны. Сугыш туктауга ярты гасырдан артык гомер узса да, бу дәһшәтле көннәр бер генә дә исеннән чыкмый. Шул кадәр гомер бер кул белән гомер иткәндә моның башкача булуы мөмкин дә түгел шул. Каты яраланып госпитальдә яткан көннәре, хәрби табибның «кулыңны кисмичә мөмкин түгел» дигән карарын аңа җиткергәч, якты көннәрнең караңгы төнгә әверелүе, бер кул белән ничек яшәрмен дип бимазалануы... Яшәргә кирәк, ихтыяр көчен туплап, тешне кысып яшәргә кирәк иде. Һади шулай итте дә. Йөзләгән ир - егете яу кырында ятып калган ярым җимерек туган авылы аны колач җәеп каршы алды: сул кулы булмаса да, акылы аек, зирәк булуын беләләр иде Кара Күлдә. Озак та тормастан, Бөгелмәдәге бухгалтерлык курсларына укырга керде ул. Шуннан соң нинди генә эш башкарырга туры килмәде Һадига. Бухгалтер булды, фермага җитәкчелек итте, озак еллар комплекслы бригадада бригадир булды, гомумән, гомер буе җаваплы вазифалар башкарды. Ә хуҗалыкта аның нинди дә булса эшне башкармыйча калуын яисә берәр төрле сәбәп буенча йөзенә кызыллык китерүен хәтерләмиләр.

Хәер, хезмәтендә генә түгел, гаиләсендә дә җаваплы гаилә башлыгы, үрнәк, кайгыртучан ата, яхшы ир була белде. Күрше Салдакай авылы кызы Өммегөлсем Һадиның кулсыз булуын зур кимчелеккә санамыйча, аңа кияүгә чыгарга ризалык бирде. Гаиләдә бер - бер артлы биш бала туды. Хуҗалыклар берләшкәч, Исхаковлар Кәкре Атауга күченделәр. Гаилә тормышында авыр минутлар да, шатлыклы - сөенечле вакыйгалар да аз булмады. Исхаковлар балалар дип, алар исән - имин килеш, чын кеше булып үсеннәр дип яшәделәр. Балалары исә йөз кызартмадылар: тормышта барысы да үз урыннарын таптылар. Хәзер инде әби - бабаларын шатландырып оныклары үсә. Әле менә күптән түгел этиләре, бабаларының 70 еллыгы уңаеннан төп нигезгә җыелган балалары, оныклары, туганнары шуларның барысын да кабат исләренә төшерделәр, этиләре адресына җылы сүзләрен кызганмадылар. Ә гомере буе балалар дип яшәүче ата өчен монардан да зуррак сөенечнең булуы мөмкинме соң? Хәер, Һади Шакирович гомерендә мондый шатлыклы мизгелләр алга таба да кабатланыр әле. Ник дигәндә, сәламәтлеге бар, кәефе көр әле картның. Элеккечә үк аралашучан, эшчән. Җиде дистәсен тутырса да, йорт тирәсендәге бөтен эшне кырып - себереп эшләп тора, кирәк булганда хуҗалыкка да ярдәмгә килә. Соңгы вакытта авыл халкы аның моңлы итеп азан әйтүен дә, мәчеткә йөрүче иң актив картларның берсе булуын, яшьләрне динне санларга, хөрмәт итәргә өйрәтүен дә хуплыйлар. Хәер, абруй да аңа кичәле - бүгенле генә килгән нәрсә түгел, ә еллар буена тупланган хөрмәт.

Р.МИНАПОВА.

## Бер хуҗалык хәбәрләре

# ЯҢА ЫСУЛ ФАЙДАГА

Яшь терлекләрне салкын ысул белән тәрбияләү «Чирмешән» КХАсы терлекчеләрендә дә киң яклау тапты. Районда беренчеләрдән булып алар бу яңа ысулны куллана башладылар. Инде беренче нәтиҗәләр дә бар. Беренче бригададан Сәрфия Нурмөхәмммәтова белән Нәфилә Хөснуллина үзләре караган 55 баш бозауның һәркайсыннан уртача 1040 грамм тәүлеклек үсеш алуга ирештеләр. Икенче бригададан Ульяна Хворостьева да үз карамагындагы 60 баш бозаудан 762шәр грамм тәүлеклек үсеш алган. Биредә салкын ысул белән тәрбияләү өчен янә 24 баш яшь терлеккә исәпләнгән торак сафка баскан. Яңа ысулның (хәер, бозауларны салкында асрау Кәкре Атаудагы сөтчелек комплексы терлекчеләре өчен яңа түгел, моннан ун еллар элек алар бу методны кулланып караганнар иде инде) уңай һәм тискәре яклары хакында сорагач, хуҗалыкның яңа зоотехниты Р.И.Сиражетдинов яшь бозауларны салкында асрап фәкать файда гына күрүләре хакында сөйләде. Беренчедән, үлем - китем юк, аннан һәр яклап экономия, диде ул. Бу чыннан да шулай. Салкын ысул белән үскән терлекләр 18 айда ук тиешле авырлыкка җитәләр, иртә өлгерәләр. Гадәти ысул белән тәрбияләнгән, тәүлеклек үсеше 400 - 500 граммнан артмаган терлекләргә җитлегү өчен 24 - 26 ай чамасы вакыт кирәк. Ә бу, мәгълүм ки, турыдан - туры продукциянең үзкыйммәтендә чагыла.

Яңа елның беренче ае хуҗалыкның сөт җитештерүчеләре өчен дә уңышлы узды. Монарчы бозаулату бүлегендә эшләгән, хәзер савым сыерлары группасына күчкән Зөлфия Сиражетдинова үзе караган беренче кат бозаулаган таналардан 414,2шәр килограмм сөт савып алган. Бу - хуҗалыкта иң яхшы күрсәткеч. Икенче урында хуҗалыкның Гәйтән бригадасыннан Валентина Герасимова. Аның күрсәткече 341,8 килограмм. Хуҗалык буенча гыйнвар аенда бер баш сыердан савылган сөт исә 233,4 килограмм тәшкил итә.

Ж.ШАКИРОВ,
хәбәрче.

## Яз ишек кага

# ЭШ АХЫРГА ТАБА БАРА

Озак та үтмәс, кырлар мотор гөрелтесенә күмелер һәм безнең кышкы чорда ничек эшләвебезгә имтихан башланыр. Алдан ук шуны әйтәсем килә: безнең хуҗалыкның Кәкре Атау бригадасының язгы кыр эшләренә хәзерлеге яхшы. Механизаторлар күптән инде авыл хуҗалыгы машиналарын төзәтеп куйдылар. Бу эштә слесарьлар агалы - энеле Рәлиф һәм Мансур Шәйдуллиннар, Зәки Садыйков, токарьлар - аталы - уллы Хәмзә һәм Хәлил Шакировлар, эретеп ябыштыручы Фәнис Нурмөхәммәтовтан торган звено аерусча өлгер булды.

Хәзер бригаданың барлык механизаторлары тракторлар төзәтү белән мәшгульләр. Ә бу төр техника бездә аз түгел - җәмгысе 50ләп җыела. Билгеле инде, һәр хуҗалыктагыча бездә дә финанс кыенлыгы эшкә һәрчак аяк чалып тора. Әмма һәркем тырыша: баш инженер Хәмит Насыйбуллин, бригадирның техника буенча ярдәмчесе Хәлим Хәйруллин запас частьләр кайтарту хәстәрен күрсәләр, эшкә контрольлек итсәләр, механизаторлар үзләре көне буе техника тирәсендә әвәрә киләләр. Бу - бригаданың язгы кыр эшләрен тулы хәзерлек белән каршылаячагына өметне ныгыта.

Дөрес, безнең Гәйтән бригадасында техника хәзерләү белән хәл кыенрак тора. Әмма Кәкре Атау бригадасында ремонт эшләрен тәгәлләп, бөтен булган көчне икенче бригадага ярдәмгә «ташлаганда» ремонт эшләрен үз вакытында башкарып чыгу мөмкин булачак.

И.ХӘНИЕВ,
«Чирмешән» КФХАсы
рәисе.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Югары Норлат авылында яшәүче кадерле әниебез **Асия Әхмәткәрим кызы Әхмәтсафинаны** чын күңелдән олы юбилее белән котлыйбыз.

Бүген,әнкәй, сиңа 60 яшь!
Уйнап - көлеп кенә үтмәгән
Сиңа насыйп булган бәхет, шатлык,
Якты көннәр әле бетмәгән!
Яшә әле җирдә аяк терәп,
Күкрәк киереп - шуңа хаклысың!
Һаман әле безне кайгыртасың,
Безнең тынычлыкны саклыйсың.
Җаның тыныч, күңелең һәр чакта көр,
Исәнлегең корычтай булсын!



**Балаларың исеменнән улың Нәфис.**

## Белдерү

**«Алсу» кибете ГАЗ - 53 двигательләренә запас частьлар, терсәкле валлар, йөртүле дисклар, су насослары һәм башка запас частьлар сата. Төрлечә, шул исәптән «Ак Барс» вексельләре белән дә түләп була. Лицензиябез А -96 сер., № 104160.** Адрес: Школьная ур.,31.

# Профилакториебез оҗмахка тиң

Бүгенге финанс кытлыгы заманында без, гади кешеләргә ерактагы зур санаторийларга бару турында хыялланырга гына кала. Әмма андый категория кешеләрне шатландырасым килә: санаторийларга путевка эзләп иза чикмәгез, тотыгыз да Норлаттагы НУРБ санаторий - профилакториена килегез. Биредә яхшы дәва да алырсыз, өстәвенә, байтак акчагыз да янга калыр.

Биредә ел саен берничә йөз кеше ял итеп, сәламәтлекләрен ныгыталар. Алар арасында нефтьчеләр, төзүчеләр һәм башка һөнәр кешеләре бар. Өлкән яшьтәгеләр дә байтак.

Былтыр җәй санаторийның ләм белән дәвалау корпусына реконструкция үткәрелде. Дөрес, аның икенче катында эш тулысынча тәгәлләнмәгән әле. Әмма беренче катында дәвалау шартларының яхшыруы күзгә бәрелеп торырлык. Ләм, су белән дәвалау бүлмәләре киңәйтелгән. Биредә булып чыкканнан соң үзеңне яшәреп киткәндәй хис итәсең.

Гомумән, узган җәй әлеге дәвалау учреждениесендә үткәрелгән ремонт нәтиҗәсендә төп корпус та, кем әйтмешли, елмаеп, көлеп тора. Идәнгә җәелгән ачык бизәкле келәмнәр, стеналардагы затлы обойлар, чәчәкләр, чиста урын - җир, башка уңайлыклар дәваланучылар кәефенә уңай йогынты ясый. Балансланган туклану, хезмәт күрсәтүче персоналның һәр кешегә җылы мөнәсәбәте дә күңелдә соклану уята. Теш табибы Разия Йосыповна Вәлиева чагыштырмача яшь белгеч булса да, үзенә тапшырылган эш участогы өчен җаваплылыгы көчле. Баш табиб - Равия Исхаковна Шабаева кабинеты янында да халык һәрчак күп була. Өч дистә елга якын авыруларны электр белән дәвалаучы Әкълимә Хәсәншина, массажлаучы Нурия Фәтхетдинова, пешекче Светлана Осипова, хезмәт күрсәтүче персоналдан Надежда Курякова, Зинаида Наумова адресына да мактау сүзләрен күпләп әйтеп булыр иде. Биредә дәваланган һәр кеше алар эшеннән канәгать.

Гомумән, дәва алу өчен ерак йөрмәгез, якташлар. Тәвәккәлләгез дә, безнең санаторий - профилакторийга рәхим итегез, үкенмәссез.

Р.РӘХМӘТУЛЛИН,
НУРБ эшчесе.

# Әлегә банкрот түгелләр...

***«Норлатта берничә оешма банкрот дип игълан ителгән, диләр. Шулар хакында тулырак мәгълүмат бирә алмассызмы?»***

Р.САФИНА,
Норлат шәһәре.

**Укучыбызның соравына җавап бирүен үтенеп, без Октябрь районы буенча Дәүләт салым инспекциясе начальнигы Г.Ә.Миннегалиевка мөрәҗәгать иттек.**

- Укучыбыз хәбәрендә бераз төгәлсезлек бар. Сүз Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм җирле бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга зур әҗәтле калган оешма - предприятиеләр хакында бара. Октябрь районы буенча салым инспекциясе һәм Россия Федерациясе салым полициясе службасының Татарстан Республикасы буенча Чистай районара берләшмәсе, телгә алынган әҗәтләрен вакытында түли алмаулары сәбәпле, аерым предприятие - оешмалар мөлкәтенә арест салды. Узган елның сентябрендә шундый арест Төрнәс эшкәртү предприятиесенә, Норлат шикәр заводына һәм ит комбинатына салынган иде. Сүз уңаеннан, ул чорга шикәр заводының бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга бурычы 7 млрд. 763 млн .сумга җитте.

25 ноябрьдә әлеге исемлеккә Норлат юл ремонтлау - төзү идарәсе дә өстәлде.

Быел февраль аенда исемлек тагы артты. Анда Норлат машина төзү заводы, сөт - май комбинаты (бурычы 3 млрд 317 млн. сум), 53 нче СМУ да кушылдылар. Мөлкәткә арест салыну - оешма - предприятиеләр әлеге мөлкәт белән безнең рөхсәттән башка идарә итә алмыйлар, дигән сүз. Оешма - предприятие бурычларны әлеге мөлкәтне сатып түли ала, ә ничек тә түли алмаган очракта махсус комиссия аны банкрот дип игълан итә һәм әлеге мөлкәтне сатып акчасын салым түләүгә юнәлтә ала. Әмма эш аңа барып җитәр дип уйламыйбыз. Хәзер әлеге оешмалар һәрберсе үзенчә әҗәтне каплау юлларын эзлиләр, беренче кертемнәрне ясаучылар да бар инде.

## Сәнгать кешеләре

*Атарга да өлгермәде,*
*Чәчкәсен койды гөлем,*
*Тик шулай да чәчкә ат дип,*
*Таңнарда исте җилем...*

Җырчының күкрәк түреннән агылып чыккан моңлы тавышы тамашачыларны сагышландыра, моңландыра, уйландыра. Аны тыңлаган саен тыңлыйсы, чишмәдәй агылып, ургылып чыккан шушы сихерле, тылсымлы моң дулкынында эреп югаласы килә. Көндәлек тормышта ал - ялны белмәгән, шуңа да атлап түгел, ә һәрчак йөгереп йөрергә мәҗбүр Сания исә сәхнәгә чыктымы, танымаслык булып үзгәрә дә куя. Әйтерсең лә, гомер буе шулай матур киенеп, сәхнәләрдә генә чыгыш ясаган, әйтерсең лә бүтән дөньяви мәшәкате дә булмаган. Шуңа да концерттан соң «Сания, ничек итеп картаймавыңның серен әйт әле» дип сорасалар, ап - ак тешләрен җемелдәтеп елмая да:

- Җырлап яшим мин. Җыр - сердәшем дә, киңәшчем дә, юатучым да, - ди.

Ә җыр - моңга омтылыш яшьтән көчле булды аңарда. Туган авылы Бикколдан Кизләүгә йөреп укыганда беренче тапкыр сәхнәгә менде кыз. «Кара урман» җырын ничек тырышып башкаруы әле дә хәтерендә Саниянең. Көчле алкышладылар аны, артист булырсың әле дип күңелен дә үстерделәр. Әмма гади авыл кызы өчен бу сүзләр татлы хыял гына иделәр шул. Дөнья мәшәкатенә чумды Сания. Кияүгә чыкты, бер - бер артлы өч бала биләде. Аларны әле чит кешеләрдә, әле туганнарында, әле барысын бергә калдырып, көне буе эш белән мәшгуль булды ул: ә инде ун елдан соң гади кибетчедән хуҗалык товарлары кибете мөдире булып «үскәч», ерак шәһәрләрдән кайтып та керми иде.

- Бөтен борчу - шатлыкларымны җырга сала идем,- ди Сания ханым үзенең җыр көйли - көйли юл йөргән елларын искә алып.

Икенче тапкыр сәхнәгә шактый ук урта яшьләрдә күтәрелде ул. Коллективларда үзешчән сәнгатьнең көчәйгән чагы иде.

- Булдырасың бит, җырла әле, Сания апа,- диделәр аның кулы астында эшләүче кызлар.

Озак үгетләргә мәҗбүр итмәде ул хезмәттәшләрен. Башта райпода чыгыш ясады, аннары район мәдәният йортында. Тора - бара районда оештырылган бер генә татар концерты да аңардан башка үтми башлады. Концерт бригадалары составында кайсы гына авыл мәдәни учреждениесендә җырламады ул. Программа нигезендә генә чыгыш ясамыйча, сорап - сорап та җырлата башладылар үзен. Татарстан телевидениесе, радиосы буенча да яңгырады Сания Котдусова язмалары. Аккомпаниаторы Зөфәр Мифтахов, район мәдәният бүлеге мөдире Комунелла Изотова да үзешчән җырчының ходай мул итеп биргән сәләтен ача, осталыгын камилләштерә бардылар. Сания дә үз өстендә армый - талмый эшләде. Тора - бара үзенчәлекле бер оештыручыга әверелде. «Казан» санаториенда дәваланганда ул оештырган концерт - кичәләрнең берничәсендә генә булырга өлгергән дәвалау бүлеге мөдире санаторийда сәнгать бүлеге оештыручысы булып эшләргә калырга да үгетләп карады Санияне. Әмма шәхес буларак та, җырчы буларак та таныткан Норлатын ташлый ала димени инде ул? Ә балалары? Аларны күрмичә яши алмавы җырламыйча яшәүгә тиң бит. Бүген үк өздереп җырлаучы нәни оныгы Энҗе, кызы Гүзәлнең әбиләренекедәй челтерәп аккан чишмәне хәтерләтүче тавышка ия кызлары - дүрт онының сәхнәдән төшмәүләренә чын күңеленнән сөенә Сания апа. Хәер, уллары да сәнгатьтән ераклар түгел. Улы Рөстәм баянда уйнаса, кечесе Рәүхәт гитараны үзенә буйсындыра. Кайчак әниләренә кушылып җырлыйлар да. Ә инде гаилә бергә җыелса, тулы бер концерт бригадасы оеша да куя.

Ә менә быелгы Рамазан аенда Санияне кунакка чакыручылар аеруча күп булды - аның тарафыннан әйтелгән моңлы мөнәҗәтләрне еламыйча гына тыңлаучылар булмый иде ураза мәҗлесләрендә.

Сания апа күр күңелле, җитез кеше. Шулай булмаса, пенсиягә чыгуына да карамастан, үзе әйтмешли, йөгерә - йөгерә эшләп йөрер идемени?

- Хезмәт тә, җыр да минем өчен җан дәвасы,- ди Сания апа. - Аларның берсе икенчесеннән аерылгысыз.

Әнә, бүген дә сәхнәдә Сания апа. Фәридә Кудашева башкарган һәм соңгы вакытта Котдусова репертуарында нык лы урын алган «Таулар җыры»н Сания апа кебек тылсымлы итеп җырлаучылар бик сирәктер, мөгаен, «Муел», «Кәккүк» һәм башкалар да шулай ук.

*«Әгәр дә мин бер гөл булсам*
*Ал чәчәк атар идем.*
*Атлап түгел, яшьлегемә*
*Йөгереп кайтыр идем»,*

дип сагышлана җырчы күкрәк түреннән агылып чыккан тавышында. Яктылыкны, сәнгатьне, кешеләрне, изге туган җирен, тормышны яратуы чагыла бу җырда. Яшьли кабынып та тиз сүрелгән яшьлек мәхәббәте, ялгыз канатлы гомере өчен сагыш та сизелерлек. Аның бу җырын тыңлаганда залда утырган һәр кеше күзгә күренмәс җепләр белән үз язмышын күз алдыннан кичерә, ата - бабаларыбыз язмышына, халкыбыз моңнарына берегүен, бәйләнүен сизә. Җырла Сания апа, моңлан, сөендер безне.

**Р.ГИНЯЕВА.**

Спорт Спорт Спорт

## Бәйгеләрнең ахыргысы түгел

Март - чаңгы спортына нокта куючы ай. Әмма аның беренче яртысында без гадәттә берничә тапкыр ярышлар үткәреп калабыз. Ай башында, мәсәлән, традиция буенча район мәгариф бүлеге призына үткәрдек без аны. Һава шартларының әйбәт торуы сәбәпле, бәйгегә командалар байтак җыелды. Ярыш үзе дә мавыктыргыч булды, бөтен таләпләр нигезендә узды. Егетләр арасында командада беренчелегендә беренче мәктәп җиңүче булды. Дүртенче һәм Каравыл Тавы урта мәктәпләре исә икенче - өченче урыннарны яуладылар.

Кызлар командалары арасында өченче мәктәпнекеләргә тиңнәр табылмады. Дүртенче һәм Богдашкино мәктәпләре кызлары да уңышлы чыгыш ясап, команда беренчелегендә икенче һәм өченче урыннарны бүлеште.

Шәхси беренчелектә егетләр арасында В.Емелин (1 нче мәктәп) беренче, А.Ерепов (1 нче мәктәп) икенче, И.Сәйфетдинов (4 нче мәктәп) өченче урыннарга чыксалар, кызлар арасында өченче мәктәптән С.Бурнаевская бирелгән араны иң тиз үтүче булып танылды. Дүртенче мәктәптән Н.Васильева, Богдашкинодан Е.Белова икенче - өченче урыннарны алдылар.

Соңыннан оста чаңгычыларны район мәгариф бүлеге методисты Р.Рәхмәтуллин сәламләде һәм аларга бүләкләр тапшырды.

Спорт сөючеләр күңелләрен төшермәсеннәр: бу бәйге чаңгы спортындагы соңгы бәйге түгел әле. Мартның 9нда һәм 16 сында алар тагын чаңгы ярышларын күзәтә алачаклар.

## Хоккей : соңгы очрашулар

Шәһәр мәктәпләре арасында ике түгәрәктә алкалы хоккей буенча ярышлар тәмамланды. Алар хоккейның балалар ярата шөгыльләнә торган уен төре булуын тагын бер кат раслады. Ярышлар өч яшь группасында узды. Иң элек шуны әйтәсем килә, уеннарда шәһәрнең беренче һәм дүртенче мәктәпләре үзләрен аеруча оста хоккейчылар итеп таныттылар. Коллективларның беренчесе өлкәннәр һәм кече яшьтәгеләр группасында ике икенче, урта яшьтәгеләр арасында беренче урыннарны яуласалар, дүртенче мәктәп командасы хоккейчылары исә һәр өч яшьтәгеләр арасында да өченче урыннарны алдылар. Икенче мәктәп командасының өлкән яшьтәгеләр группасы беренче булса, урта яшьтәгеләр арасында икенче урынны яулады. Өченче мәктәп командасы бер призлы урын белән канәгатьләнде: аның кече яшьтәгеләр командасы беренче урынны алды.

Хөкемдарлар коллегиясе оста уенчыларны да билгеләде. Шәһәрнең беренче мәктәбеннән Д.Воскобойников, икенче мәктәптән И.Фәйзуллин, А.Ендиряков, Л.Мөлеков «сезонның иң яхшы хоккейчылары» дип табылдылар.

**Ә.НӘБИУЛЛИН.**

**Рәсемдә: уенның кызган чагы.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**




**Идел Буе региональ наркология үзәге**

**Табиб М.Б.Багрянцев.**

**Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.**

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көнне, 14 мартта көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.

Белдерүләр

### Сатабыз

**Райпоның хәзерләүләр конторасы кибетләрендә сатуда яшелчә һәмсуган орлыклары, орлыклык суган бар.**

Администрация.

***

**2000 километр йөргән яңа ВАЗ - 21083. Бәясе 40 миллион, 1997 елның 13 февралендә рәсмиләштерелгән.**

Тел.: 2 - 17 - 43.

***

**Печән һәм сепаратор.**

Адрес: Маяковский ур., 12.

### Алмаштырабыз

**Ике бүлмәле фатирны - ашыгыч тәстә ике берәр бүмәлегә.** Тел.: 5 -20 - 15 (шимбә һәм якшәмбедән кала иртәнге 8 дән кичке 5 нче яртыга кадәр).


## Кем инде кәбестәне кәҗә абзарында саклый?




Вена властьлары бервакыт шәһәр полициясе составында хатын - кызлар подразделениесе булдырырга карар кылалар. Тиз арада махсус курсларга 60 кыз җыйнала да. Кызларны шәһәр полицейскийлары эшли торган иң зур казармаларга урнаштыралар. Ир - ат осталары да шунда ук, бары тик башка катларда гына яшиләр. Кызлардан аерым, янәсе. Тик кызлар подразделениесе вазифаларын башкарута керешер вакыт җиткәч кенә, араларында эшләрдәйләре аз булуы ачыклана. Кызларны курсларга кабул итүдән соң берничә атна үтү белән 19 - 25 яшьлек, әле кияүдә булмаган ул 60 кызның 36сы... йөккә узганлыгы билгеле була.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2083 данә. Заказ № 6024